РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«22» июня 2021 г. г. Альметьевск № 62

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 83 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә премия бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль вазыйфа биләп торучы затларның эшчәнлеген стимуллаштыру тәртибен камилләштерү максатларында

Әлмәт муниципаль Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 10 августындагы 83 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә премия бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 6 октябрендәге 129 нчы номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 146 нчы номерлы, 2018 елның 31 маендагы 243 нче номерлы, 2019 елның 28 августындагы 313 нче номерлы, 2019 елның 30 сентябрендәге 324 нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга 3 нче кушымтада:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.3 пунктча өстәргә:

«2.3. Озак вакытлы авыру һәм муниципаль хезмәткәрләрнең дәвалануы белән бәйле авыр тормыш ситуациясе килеп чыккан очракларда, тотылган чыгымнарны раслый торган медицина оешмаларыннан документлар бирелеп тиешле шартлар үтәлгәндә (хезмәткә сәләтсезлек кәгазе, эпикриз, медицина хезмәте күрсәтү турында шартнамәләр күчермәләре, касса чеклары, квитанцияләр).»;

б) түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«11. Муниципаль хезмәткәрнең озак авыруы һәм аның дәвалануы белән бәйле рәвештә бирелүче матди ярдәм бер айлык акча күләмендә түләнә.».

Заказ № 2625

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Грушин А.И.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов